**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

_______ _____________

Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1,24,28 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2018 елның 17 июлендәге 29-09 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районында ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районының Актаныш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

2. Ачык тыңлауларны үткәрү срогын 1 көндә үткәрүне билгеләргә.

- ачык тыңлаулар уздыру вакыты - 2023 елның 18 августы:
- 09:00 сәгатьтә, үткәрү урыны: хакимият бинасы, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 17 йорт;

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге җитәкчесе - А.К.Галиәхмәтовны ачык тыңлаулар уздырган өчен җаваплы итеп билгеләргә.

4. Актаныш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен, кушымта нигезендә расларга.

5. Әлеге карарны районның рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга һәм «Актаныш Таңнары»газетасында ачык тыңлаулар үткәрү турында мәгълүмат бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
_______ 2023 ел, №___
кушымта

Актаныш авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

Әлеге Тәртип Актаныш авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү (алга таба Генераль план) максатларында эшләнгән һәм авыл җирлеге гражданнарының җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча фикер алышуда катнашу тәртибен, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча фикер алышуда, халыкның җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлауларда катнашуы һәм авыл җирлеге халкының Актаныш районы Башкарма комитетына җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрүе юлы белән бара.

2. Җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләре проектының график һәм текст материаллары экспозициясе Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылган.

3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча материаллар белән танышу: дш. - җм. 9.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты fgis.economy.gov.ru территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

5. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итү 2023 елның 24 июленнән алып 2023 елның 14 августына кадәр түбәндәге адрес буенча башкарыла: 423740, ТР, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 17 йорт, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, инфраструктура үсеше бүлеге;

6. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү, шулай ук җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итү һәм исәпкә алуны ачык тыңлауларны үткәрү өчен җаваплы кеше башкара.

7. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча фикерләрне, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итүне ачык тыңлаулар секретаре гамәлгә ашыра.

8. Ачык тыңлаулар башланганчы секретарь тарафыннан ачык тыңлауларда катнашучыларны теркәү башкарыла. Теркәлү битендә ачык тыңлауларда катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны адресы күрсәтелә.

9. Ачык тыңлаулар уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
- докладчыга төп доклад өчен 20 минуттан да артык бирелми;
- җирдән файдалану һәм җирлектә төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты турында фикер алышу өчен чыгышлар өчен 3 мин тан да артык түгел;
- репликалар һәм искәрмәләр өчен - 2 минуттан артык түгел.

10. Ачык тыңлаулар уздырганда секретарь тарафыннан җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе алып барыла. Беркетмәне оештыручы һәм ачык тыңлаулар секретаре имзалый.

11. Ачык тыңлауларны оештыручы ачык тыңлаулар уздырылганнан соң 2 көн эчендә ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- халык тыңлауларына чыгарылган мәсьәләнең исеме;
- ачык тыңлаулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны;
- ачык тыңлауларда катнашкан авыл җирлеге гражданнары саны;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча карар.

12. Бәяләмәгә ачык тыңлауларны оештыручы кул куя һәм ачык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә «Актаныш таңнары» газетасында, районның рәсми сайтында, Актаныш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында мәҗбүри рәвештә бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.